РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**

**Кирельского сельского поселения**

***Камско-Устьинского***

**муниципального района**

Улица Гагарина, дом №1, Камско-Устьинского района,
422827, Республика Татарстан
Телефон 8 (277) -367-45.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

***Кама Тамагы***

**муниципаль районы**

**БАШЛЫГЫ**

**Кирельского сельского поселения**

Гагарина Ур, Кама-Тамагы район, 422827,
Республика Татарстан
Телефон 8 (277)- 367-45.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 елның 22 ноябре**

**№ 2**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлегенең Ишем авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә КАРАР бирәм:

1. 2019 елның 5 декабрендә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлегенең Ишем авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлегенең Мордва Каратае авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм 1 төркем

инвалидлардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

- поселок эчендәге һәм урамара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны ТР, Кама Тамагы районы, Мордва Каратае авылы, Центральная урамы, 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

“Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Кирельский авыл җирлеге”
муниципаль берәмлек башлыгы Ф. Я. Зиннәтуллин